МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

_29.08.2022__ г.Казань № __811__

ТР Юстиция министрлыгында 2022 елның 23 сентябрендә 9494 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 16 июлендәге 473 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы пенсионерларының аерым категорияләрен ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юллама алу өчен исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалануына юллама алу өчен Татарстан Республикасы пенсионерларының аерым категорияләрен исәпкә алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 16 июлендәге 473 санлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 10.08.2016 №465, 14.05.2018 №363, 10.10.2018 №935, 22.01.2019 №45, 03.04.2019 №226, 05.08.2019 №595, 23.10.2019 №888, 14.07.2020 №514, 28.09.2020 №680, 08.09.2021 №645, 14.02.2022 №102 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалануына юллама алу өчен Татарстан Республикасы пенсионерларының аерым категорияләрен исәпкә алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге боерык 2022 елның 1 ноябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2022 елның 29 августындагы 811 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы пенсионерларының аерым категорияләрен ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юллама алу өчен исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 16 июлендәге 473 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы пенсионерларының аерым категорияләрен ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юллама алу өчен исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1 бүлектә:

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә (мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган үткәрә торган анкета нәтиҗәсендә билгеләнгән мөрәҗәгать итүченең тиешле билгеләренә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү) мөрәҗәгать итүченең профилен яңасына үзгәртү үткәрелми.»;

1.4.1-1.6 пунктларын үз көчен югалткан дип танырга;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы

Татарстан Республикасы пенсионерларының аерым категорияләрен ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юллама алу өчен исәпкә алу.

2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исеме

Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округында мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча Социаль яклау идарәсендә (бүлегендә) (алга таба – Идарә (бүлек)) күрсәтелә.

2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юллама алу өчен исәпкә кую турында яисә

ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юллама алу өчен исәпкә куюдан баш тарту турында карар тора (әлеге Регламентка 3 нче кушымта).

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе «Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасында теркәлә.

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе аны алу буенча сайланган ысул белән мөрәҗәгать итүчегә бирелә (җибәрелә):

язмача формада мөрәҗәгать итүчегә шәхсән яисә почта аша;

«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) нигезендә имзаланган электрон документ формасында электрон почта адресы буенча һәм (яки) мөрәҗәгать итүченең Бердәм порталда яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинетына.

## 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты

2.4.1. Гариза һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан почта аша җибәреп яисә шәхсән тапшырылган булса, дәүләт хезмәте гаризаны һәм документларны теркәгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көнлек чорда күрсәтелә.

Гариза һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан Бердәм порталда яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинеты аша җибәрелгән булсалар, гаризага теркәү номеры беркетелгән көннән башлап, эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көнлек чор бирелә, ул Бердәм порталда яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинетта чагылдырыла.

2.4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты әлеге Регламентның 2.6.2 пунктында күрсәтелгән ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында сорала торган документлар (белешмәләр) булмаган очракта, 20 эш көненә озайтыла.

## 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр

Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталында урнаштырылган:

дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр;

Идарә (бүлек), шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт граждан хезмәткәрләре, хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат.

## 2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

2.6.1. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән тапшырыла торган, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар:

ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юллама белән тәэмин итү турында гариза (алга таба – гариза):

әлеге Регламентка $1^1$ кушымта нигезендә кәгазьдә документ формасында;

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы һәм Бердәм портал аша мөрәҗәгать иткәндә, электрон формада (Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында һәм Бердәм порталда, гаризаны нинди дә булса башка төрле формада өстәмә тапшыру зарурлыгыннан башка гына) интерактив форманы тутыру юлы белән), әлеге пункт таләпләре нигезендә имзалап;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турында нигезләмә раслау хакында» 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында халыкның аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турында нигезләмә кушымтасының 1 пунктындагы өченче абзацта һәм 2 пунктының бишенче һәм тугызынчы абзацларында күрсәтелгән керемнәрне раслый торган документлар (әлеге документлар булган очракта);

Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән күчемсез милек объектларына хокук билгели торган документларның күчермәләре (булган очракта);

мөрәҗәгать итүчедә законнар нигезендә мөрәҗәгать итүче белән бергә яшәү мөмкинлеген бирми торган, Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән хроник авыруның катлаулы формасы булуы турында белешмә (мөрәҗәгать итүчедә шундый авыру булган очракта).

Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.

Документлар һәм белешмәләр мөрәҗәгать итүче тарафыннан тиешле оешмалардан – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә дә алына.

Документларның күчермәләре, әгәр алар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм Идарә (бүлек) белгече тарафыннан таныклана.

Гаризаны Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Бердәм портал аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүченең яки аның законлы вәкиленең шәхесен таныклаучы документтан белешмәләр Электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификация һәм аутентификация бердәм системасындагы (алга таба – ИАБС) исәпкә алу язуын раслаганда тикшерелә.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе аша Идарәгә (бүлеккә) тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

шәхсән яисә почта аша кәгазьдә;

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында, Бердәм порталда шәхси кабинет аша гариза формасын тутыру юлы

белән Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Бердәм портал аша электрон формада;

гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша (алга таба – «Интернет» челтәре).

Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Идарәгә (бүлеккә) шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) рәсми сайтында http://mtsz.tatarstan.ru урнаштырылган.

Гаризаны Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша бирелгән очракта, әлеге пунктта күрсәтелгән документларның электрон үрнәкләре яки электрон формадагы документлар мондый документларны булдыру һәм имзалау өчен вәкаләтле булган затлар, шул исәптән нотариуслар тарафыннан да, 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланган булырга тиеш.

Гариза һәм документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) $21^1$ һәм $21^2$ статьялары таләпләренә туры китереп, электрон имза белән кул куелган электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да, тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

Мөрәҗәгать итүчеләр, гаризаны һәм кирәкле документларны гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре ярдәмендә, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да, һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Бердәм портал аша җибәргән очракта, гаризаны гади электрон имза белән имзалыйлар. Гади электрон имзаны алу өчен, мөрәҗәгать итүчегә ИАБС системасында теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр исәпкә алу язуын расларга кирәк.

2.6.2. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алына торган документлар (белешмәләр):

«Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнар нигезендә пенсия билгеләү хакында (вәкаләтле органнарда);

күчемсез мөлкәт булуы турында (Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында булган);

транспорт чаралары, үзйөрешле транспорт чаралары һәм башка төр техниканың булуы турында (вәкаләтле органнарда);

торак бинаны билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип тану турында (Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында булган);

шәхси счетның иминият номеры турында (вәкаләтле органнарда);

гражданинның уртача айлык керемен исәпләгәндә исәпкә алына торган керемнәр турында (вәкаләтле органнарда);

шифаханә-курорт дәвалавына мохтаҗлык турында медицина күрсәткечләре булуы турында (шифаханә-курорт дәвалавына медицина күрсәткечләре булуы турында мәгълүмат алмашу мәсьәләсе буенча ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кертелгәннән соң);

Россия Федерациясе бюджет системасына салымнар, җыемнар буенча бурычлар булмавы турында (вәкаләтле органнарда).

Мөрәҗәгать итүче Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта, ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша өстәмә рәвештә түбәндәге белешмәләр алына:

мөрәҗәгать итүче паспортының дөреслеген раслау турында (вәкаләтле органнарда);

мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча теркәлүенең дөреслеген раслау турында (вәкаләтле органнарда).

Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.

Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында билгеләнгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

## 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.7.1. Документларны кабул итүдән баш тарту нигезе:

әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документларны тулы булмаган күләмдә тапшырылуы;

әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән документларны гамәлдә булу чоры узган хәлдә тапшыру;

документларда Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган бетерелгән, өстәп язылган урыннар, сызылган сүзләр һәм төзәтмәләр булуы;

мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча мөрәҗәгать итмәве;

гариза һәм 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) электрон документлар рәвешендә документлар (документларның күчермәләрен) тапшыру.

күчермәләре Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган очракта, төп документларның күрсәтелмәве;

шушы Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелмәгән затның документлар белән мөрәҗәгать итүе;

гариза һәм документлар электрон формада куелган таләпләрне бозып тапшырылган очракта;

гариза формасындагы, шул исәптән Бердәм порталда яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында гаризаның проактив формасындагы кырларны тулылысынча тутырмау;

документларда булган мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмендә файдалану мөмкинлеген бирми торган бозык урыннар булуы;

гаризаның гражданнарга юлламалар бирергә вәкаләтле булмаган дәүләт хакимияте органына, җирле үзидарә органына яисә оешмага тапшырылуы.

2.7.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документлар Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталында урнаштырылган, дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүматка туры китереп тапшырылган булсалар, гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

## 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

2.8.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр исемлеге:

гамәлдә булу срогы чыккан документларны тапшыру;

мөрәҗәгать итүченең уртача айлык кеременең күләме Татарстан Республикасында билгеләнгән пенсионерның яшәү минимумы күләменең 400 процентыннан артып китүе;

мөрәҗәгать итүчедә мөлкәт белән тәэмин ителү дәрәҗәсенең «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтаның «а» - «г», «е», «ж» пунктларында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 14 февралендәге 97 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибенең 1.2 пунктындагы икенче һәм өченче абзацлары нигезләмәләрендә билгеләнгән гаиләнең (гражданинның) мөлкәт белән тәэмин ителү дәрәҗәсеннән артык булуы;

гражданинның Татарстан Республикасыннан читкә чыгып китүе;

гражданинның Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә шифаханә-курортта дәваланырга хокуклы халык категорияләренә керүе;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар һәм җыемнар буенча бурычлар булуы.

2.8.3. Әгәр дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталда бастырып чыгарылган мәгълүмат нигезендә тапшырылган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту тыела.

## 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

## 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатьне тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты

2.10.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.

2.10.2. Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

## 2.11. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатен теркәүгә алу чоры

2.11.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза гариза һәм документлар алынган көнне теркәлә.

2.11.2. Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.

2.11.3. Гаризаны Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Бердәм портал аша җибәргән очракта, мөрәҗәгать итүче гариза бирелгән көнне Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы, Бердәм порталдагы шәхси кабинетта һәм электрон почта аша гаризаның җибәрелүен раслый торган белдерү ала, анда гаризаның теркәү номеры һәм тапшыру датасы күрсәтелгән була.

## 2.12. Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

2.12.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. Көтү залларында (бүлмәләрдә) дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүматлар, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза үрнәкләре урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.

2.12.3. Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

б) дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

в) объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

д) инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объекттан һәм дәүләт хезмәтеннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм текстлы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;

ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү.

2.12.4. Инвалидларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, дәүләт хезмәтеннән файдалану алу мөмкинлеге бирү өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) дәүләт хезмәтен күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтү;

в) дәүләт хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә дәүләт хезмәтеннән файдалануга комачау итә торган каршылыкларны бетерүдә кирәкле башка ярдәмне күрсәтү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контрастлы фонда башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар, шулай ук аудиоконтур күчермәләре булу.

2.12.5. 2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

## 2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре

2.13.1. Дәүләт хезмәтенең һәркемгә күрсәтелә алырлык булуы күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Идарә (бүлек) бүлмәләренең җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашуы;

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;

белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган урыннарның да, кирәкле санда булуы;

дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталында тулы мәгълүмат булуы;

электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;

мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен электрон рәвештә алу мөмкинлеге;

инвалидларга биналарның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган башка каршылыкларны бетерүдә дәүләт хезмәте күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан ярдәм күрсәтү;

2.13.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

гаризаны һәм документларны кабул итү һәм карау чорларының саклануы;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу чорының саклануы;

Идарә (бүлек) белгечләре тарафыннан әлеге Регламентны бозуга прецедентларның (нигезле шикаятьләрнең) булмавы.

2.13.3. Гариза бирүченең Идарә (бүлек) белгечләре белән бәйләнешкә кереп, хезмәттәшлек итү күләме:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны турыдан-туры тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә – юк.

2.13.4. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гариза бирүченең Идарә (бүлек) белгече белән бер мәртәбә хезмәттәшлек итү вакытының озынлыгы 15 минуттан артмый.

2.13.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан Бердәм портал яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша алынырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәтү, хезмәт күрсәтү тәртибе һәм башка документлар турындагы белешмәләрне карау Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында «Шәхси кабинет»та мөрәҗәгать итүчене алдан авторизацияләмичә башкарыла.

Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында «Шәхси кабинет»та авторизация узганнан соң мөрәҗәгать итүченең мөмкинлекләре:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны бирергә;

кирәк булганда, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның электрон үрнәкләрен (график файлларны) беркетергә;

дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат алырга;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында мәгълүмат алырга.

Гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны электрон рәвештә бирү мөмкинлеген тәэмин итү өчен, мөрәҗәгать итүчедә гади электрон имза ачкычы булырга тиеш. Гади электрон имза ачкычын (алга таба – гади электрон имза) алу өчен мөрәҗәгать итүчегә ИАБС системасында теркәлү процедурасын узарга кирәк. ИАБС системасында алдан теркәлүнең онлайн-формасы «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтта урнаштырылган («Интернет» челтәрендәге сайтның домен исеме – esia.gosuslugi.ru/).

ИАБС системасында (физик зат буларак) теркәлү процедурасын узганнан соң мөрәҗәгать итүче – физик зат гади электрон имзаны кулланып, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында авторизация узарга тиеш. Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы «Шәхси кабинет»та авторизацияләнгәннән соң мөрәҗәгать итүче элек бирелгән гаризаларын һәм хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү нәтиҗәләрен карау мөмкинлеген ала.

2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән:

күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен исәпкә ала торган;

Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында

2.14.1. Дәүләт хезмәтен экстерриториаль принцип буенча күрсәтү гаризаларны Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәрү мөмкинлеген тәэмин итү өлешендә гамәлгә ашырыла.

2.14.2. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны Бердәм порталдан, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан файдаланып тапшырырга;

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны карау барышы турында белешмәләр алырга;

г) Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын бәяләргә;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

е) Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт граждан һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш)

шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә Идарә (бүлек), шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт граждан хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

2.14.3. Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла. Бу очракта мөрәҗәгать итүче яки аның законлы вәкиле Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында ИАБС системасында исәпкә алыну язуын раслау юлы белән авторизация уза, электрон рәвештә интерактив формадан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны тутыра.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында тутырылган гариза, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның электрон рәвешләрен теркәп, мөрәҗәгать итүче тарафыннан Идарәгә (бүлеккә) җибәрелә. ИАБС системасында авторизацияләнгән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза мөрәҗәгать итүченең, гаризаны имзалау өчен вәкаләтле мөрәҗәгать итүче вәкиленең гади электрон имзасы белән имзаланган дип санала.

Гариза Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәрелгән очракта, әлеге Регламентның 2.3.2 пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында белдерү мөрәҗәгать итүчегә, мөрәҗәгать итүченең вәкиленә Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында шәхси кабинетка Идарә (бүлек) җитәкчесенең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән таныкланган электрон документ формасында җибәрелә.

2.14.4. Электрон документлар түбәндәге форматларда тапшырыла:

а) xml - формалаштырылган документлар өчен;

б) doc, docx, odt - формулалары булмаган, текстлы эчтәлектәге документлар өчен (әлеге пунктның «в» пунктчасында күрсәтелгән документлардан тыш);

в) xls, xlsx, ods - исәпләмәләре булган документлар өчен;

г) pdf, jpg, jpeg - формулаларны һәм (яки) график сурәтләрне дә үз эченә алган (әлеге пунктның «в» пунктчасында күрсәтелгән документлардан тыш), шулай ук график сурәтләре булган документларны да кертеп, текстлы эчтәлектәге документлар өчен.

Документның үз оригиналын сканер аша уздыру юлы белән электрон документны формалаштыру рөхсәт ителә (күчермәләрне куллану рөхсәт ителми), ул 300 - 500 dpi (масштаб 1:1) мөмкинлегендә документ оригиналы ориентациясен саклап гамәлгә ашырыла, түбәндәге режимнарны кулланып:

«каралы-аклы» (документта график сурәтләр һәм (яки) төсле текст булмаган очракта);

«соры төсмерләрдә» (документта төсле график сурәтләрдән аерыла торган график сурәтләр булган очракта);

«төсле» яки «төсне тулы дәрәҗәсендә тапшыру режимы» (документта төсле график сурәтләр яисә төсле текст булган очракта);

чын нөсхәдәге барлык аутентик билгеләрне, атап әйткәндә: затның график имзасын, мөһерне, бланк чатындагы штампны саклап;

файллар саны һәркайсында текстлы һәм (яки) графикалы мәгълүматлар булган документлар санына туры килергә тиеш.

Электрон документлар түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

документны һәм документтагы битләр санын идентификацияләү мөмкинлеген;

өлешләргә, бүлекләргә, кисәкләргә (кискәчләргә) бүленгән документлар өчен эчтәлек буенча һәм (яки) текстта булган рәсемнәргә һәм таблицаларга күчү мөмкинлеген.

xls, xlsx яки ods форматларында тапшырылырга тиешле документлар аерым электрон документ рәвешендә формалаштырыла;

2.14.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.14.6. Мөрәҗәгать итүчеләрне Идарәгә (бүлеккә) кабул итүгә язу (алга таба – кабул итүгә язу) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, Идарәнең (бүлекнең) телефон номеры аша телефон элемтәсе аша гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчегә Идарәдә (бүлектә) билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә теләсә нинди буш кабул итү датасына һәм вакытына язылу мөмкинлеге бирелә.

Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен, мөрәҗәгать итүчегә система аша соралган мәгълүматларны күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

фамилиясен, исемен һәм атасының исемен (булган очракта);

телефон номерын;

электрон почта адресын (ихтыярына карап);

кабул итү көннәре, вакыты һәм урыннары.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан алдан язылу барышында күрсәтелгән белешмәләр мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә тапшырылган документлардагы белешмәләргә туры килмәсә, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Алдан язылган вакытта, мөрәҗәгать итүчегә үзе тарафыннан гаризада күрсәтелгән ысул белән, әгәр дә ул кабул итү өчен билгеләнгән вакыттан соң 15 минут узгач килмәсә, алдан язылуның гамәлдән чыгарылачагы турында хәбәр ителә.

Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша яки Идарәнең (бүлекнең) телефон номеры буенча алдан язылудан баш тартырга хокуклы.

Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификацияләүне һәм аутентификацияләүне узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен алдан ук билгеләп куелырга тиешле кирәкле вакыт озынлыгын исәпләүдә кирәкле белешмәләрне тапшырудан тыш, мөрәҗәгать итүчедән башка гамәлләр башкаруны таләп итү тыела.»

2.14.7. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә кулланыла:

«Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасы;

«Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы.

2.14.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

2.14.9. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәк (алга таба – КФҮ), КФҮ ерактагы эш урыннары аша дәүләт хезмәте күрсәтелми.

3 бүлектә:

3 бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм сроклары»;

3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Татарстан Республикасы пенсионерларының аерым категорияләрен ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юллама алу өчен исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән гариза тутыру өлешендә дә;

2) гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

3) мәгълүматлар алу, ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юллама алу өчен исәпкә кую турында (исәпкә куюдан баш тарту турында) турында карар әзерләү һәм кабул итү;

5) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен гражданин шәхсән мөрәҗәгать иткәндә (гаризаны һәм документларны почта аша җибәргәндә) бирү яки дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинетта урнаштыру.

6) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән басма хаталарны һәм ялгышларны (алга таба – техник хата) төзәтү.

Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә, мөрәҗәгать итүче өчен түбәндәгеләр тәэмин ителә:

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм вакыты турында мәгълүмат алу;

гариза формалаштыру;

гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итү һәм теркәүгә алу;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу;

гариза карау барышы турында мәгълүмат алу;

дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатын бәяләү;

дәүләт хезмәтен күрсәтә торган Идарә (бүлек) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) яисә Идарәнең (бүлекнең) вазыйфаи затлары яки дәүләт хезмәткәре гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү.

Гаризаны карау барышы турында һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында мәгълүмат алу, авторизацияләнү шарты белән, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында шәхси кабинетта гамәлгә ашырыла. Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта үз инициативасы буенча шәхси кабинетта электрон гаризаның статусын, шулай ук алга таба башкарылачак гамәлләр турында мәгълүмат карау мөмкинлегенә ия.

Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүчегә түбәндәгеләр җибәрелә:

а) гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итү һәм теркәү турында гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итү һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процедураларының башлану факты турындагы белешмәләрне, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтүне тәмамлау датасы һәм вакыты турындагы белешмәләрне яисә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән нигезле баш тартуны үз эченә алган белдерү;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны карау нәтиҗәләре турында белдерү, анда дәүләт хезмәте күрсәтү турында уңай карар кабул ителүе һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе алу мөмкинлеге турында белешмәләр яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән нигезле баш тарту була.»;

3.3.1 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.3.1. Документлар белән гаризаның керүе административ процедураны (гамәлне) башлау өчен нигез булып тора.

Мөрәҗәгать итүче, әлеге Регламентның 2.6.1 пункты нигезендә документларны теркәп, Идарәгә (бүлеккә) гариза тапшыра.

Мөрәҗәгать итүче, гаризаны Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша электрон формада тапшыру өчен, түбәндәге гамәлләрне башкара:

Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында авторизацияләү уза;

Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында электрон гариза формасын ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны яки электрон документ үрнәкләрен электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);

электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга куя);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза формасында тиешле тамга куя);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза рәвешендәге тиешле төймәгә баса);

электрон гариза әлеге Регламентның 2.6 пункты таләпләре нигезендә имзалана;

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.

Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Формалаштырылган гаризаны форматы-мантыйгы ягыннан тикшерү мөрәҗәгать итүче гаризаның электрон формасындагы барлык юлларны тутырганнан соң гамәлгә ашырыла. Гаризаның электрон формасындагы кырларны төгәлсез тутыру очрагы ачыкланганда, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында турыдан-туры гаризаның электрон формасында мәгълүмат җиткереп, хәбәр ителә.

Гаризаны формалаштырганда мөрәҗәгать итүче өчен түбәндәгеләр тәэмин ителә:

а) гаризаның һәм әлеге Регламентның 2.6.1 пунктында күрсәтелгән, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларның күчермәләрен ясау һәм аларну саклау мөмкинлеге;

б) гаризаның электрон формасы күчермәсен кәгазьдә бастырып чыгару;

в) файдаланучы ихтыярына карап, шул исәптән гаризаның электрон формасына ялгыш керткәндә һәм күрсәткечләрне яңадан кертү зарурлыгы булганда да, теләсә кайсы вакытта электрон гариза формасына элегрәк кертелгән күрсәткечләрне саклау;

г) ИАБС булмаган мәгълүматларга кагыла торган өлешендә, ИАБС системасында урнаштырылган һәм Бердәм порталда, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында басылып чыккан мәгълүматларны файдаланып, мөрәҗәгать итүче тарафыннан белешмәләр кертә башлаганчыга кадәр электрон гариза формасы кырларын тутыру;

д) элегрәк кертелгән мәгълүматларны югалтмыйча, электрон гариза формасын тутыруның теләсә кайсы этапларына яңадан әйләнеп кайту;

е) мөрәҗәгать итүченең Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында бер елдан азрак булмаган чорда үзе элегрәк тапшырган гаризаларны, шулай ук кимендә 3 ай эчендә өлешчә формалаштырган гаризаларны карау мөмкинлеге.

Формалаштырылган һәм имзаланган гариза һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документлар Идарәгә (бүлеккә) Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәрелә.

Идарә (бүлек) белгече дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган, шушы Регламентның 2.7.1 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булу-булмавын тикшерә.

Идарә (бүлек) белгече өчен электрон гаризаны алу мөмкинлеге «Татарстан Республикасы Халыкның социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасында тәэмин ителә.

Идарә (бүлек) белгече:

Бердәм порталдан, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан электрон гаризалар булу-булмавын көненә 2 тапкырдан ким булмаган ешлыкта тикшерә;

алынган гаризаларны һәм теркәлгән документлар рәвешләрен карый.

Гариза һәм документларның законнарда билгеләнгән тәртиптә таныкланган күчермәләре почта аша һәм 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланган (таныкланган) электрон документлар рәвешендә электрон почта аша җибәрелергә мөмкин.

Идарәгә (бүлеккә) почта, электрон почта, Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша карау өчен җибәрелгән гариза һәм документлар мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә гаризаны һәм документларны карау өчен билгеләнгән тәртиптә карап тикшерелә.»;

3.3.2 пунктта:

дүртенче абзацта, «(документларны почта, электрон почта аша җибәргән очракта)» сүзләреннән соң «яисә гаризаны теркәү турындагы белдерүне

мөрәҗәгать итүченең Бердәм порталдагы шәхси кабинетына яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинетына җибәрү (гаризаны Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәргән очракта)» сүзләрен өстәргә;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тарту нигезләре булган очракта, Идарә (бүлек) белгече мөрәҗәгать итүчегә документларны кайтарып бирә һәм мөрәҗәгать итүчегә, документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тартуда ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген аңлатып, документларны кабул итүдән баш тарту турында хәбәр итә. Мөрәҗәгать итүченең телдән гаризасы буенча баш тарту язмача рәвештә рәсмиләштерелә. Гаризаны һәм документларны почта, шул исәптән электрон почта, аша алганда Идарә (бүлек) белгече, документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тартуның сәбәпләрен язмача аңлатып, документларны почта, электрон почта аша кайтара. Гаризаны Бердәм портал яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша биргән очракта, гаризаны теркәүдән баш тарту турында белдерү мөрәҗәгать итүченең Бердәм порталдагы яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинетына җибәрелә.»;

җиденче һәм сигезенче абзацларда «электрон документлар рәвешендә» сүзләрен «электрон документлар рәвешендә Бердәм портал аша, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы яки «Интернет» челтәре аша» сүзләренә алмаштырырга;

3.4.2 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.4.2. Идарәдә (бүлектә) ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юллама алу өчен исәпкә алу (исәпкә алудан баш тарту) турында карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр булмаса, Идарә (бүлек) белгече, шул исәптән электрон формада да, ведомствоара электрон мәгълүмати хезмәттәшлек системасы ярдәмендә вәкаләтле оешмаларга түбәндәге белешмәләрне бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләрне рәсмиләштерә һәм юллый:

«Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнар нигезендә пенсия билгеләү хакында (вәкаләтле органнарда);

күчемсез мөлкәт булуы турында (Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында булган);

транспорт чаралары, үзйөрешле транспорт чаралары һәм башка төр техниканың булуы турында (вәкаләтле органнарда);

торак бинаны билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип тану турында (Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында булган);

шәхси счетның иминият номеры турында (вәкаләтле органнарда);

гражданинның уртача айлык керемен исәплүгәндә исәпкә алына торган керемнәр турында (вәкаләтле органнарда);

шифаханә-курорт дәвалавына мохтаҗлык турында медицина күрсәткечләре булуы турында (шифаханә-курорт дәвалавына медицина күрсәткечләре булуы турында мәгълүмат алмашу мәсьәләсе буенча ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кертелгәннән соң);

Россия Федерациясе бюджет системасына салымнар, җыемнар буенча бурычлар булмавы турында (вәкаләтле органнарда);

мөрәҗәгать итүче Бердәм портал, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта, өстәмә рәвештә түбәндәге белешмәләрне бирү турында:

мөрәҗәгать итүче паспортының дөреслеген раслау турында (вәкаләтле органнарда);

мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча теркәлүенең дөреслеген раслау турында (вәкаләтле органнарда).

Ведомствоара электрон мөрәҗәгатьне электрон документ рәвешендә формалаштыру һәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы каналлары буенча җибәрүнең техник мөмкинлекләре булмаганда, ведомствоара мөрәҗәгать кәгазьдә почта аша, бер үк вакытта почта аша яисә курьер ярдәмендә җиткерү юлы белән факс буенча җибәрелә.

Ведомствоара мөрәҗәгать 210-ФЗ номерлы федераль законның $7^2$ статьясы таләпләре нигезендә формалаштырыла.

3.4.1 һәм 3.4.2 пунктларда билгеләнә торган процедуралар гариза һәм документлар теркәлгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләр.»;

3.5.1 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура рәсми мөрәҗәгатьләргә җаваплар килгән көннән соң ике эш көне эчендә, ләкин гариза һәм документлар теркәлгәннән соң җиде эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.»;

3.5.2 пунктның икенче абзацында «алдагы процедура тәмамланган көнне» сүзләрен «ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юллама алу өчен исәпкә кую (исәпкә куюдан баш тарту) турында карар проектын имзалау өчен җибәргәннән соң ике эш көне эчендә» сүзләренә алмаштырырга;

3.6 пунктта:

өченче абзацта «телефонга смс-хәбәр итеп» сүзләреннән соң «мөрәҗәгать итүченең Бердәм порталдагы шәхси кабинетына яисә мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы шәхси кабинетына җибәрү юлы белән» сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзацта «алдагы процедура тәмамланган көнне» сүзләрен «ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юллама алу өчен исәпкә кую (исәпкә куюдан баш тарту) турында карар проектын имзалаган көннән башлап бер эш көне эчендә» сүзләренә алмаштырырга;

3.7 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.7. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документта техник хатаны төзәтү.»;

3.7.2 пунктының икенче абзацында «алдагы процедура тәмамланган көннән башлап» сүзләрен «карар проектын имзалау өчен җибәрелгән көннән алып» сүзләренә алмаштырырга;

3.7.3 пунктта:

беренче абзац «почта адресы буенча» сүзләреннән соң «электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә, телефонга смс-хәбәр белән, Бердәм

порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында шәхси кабинет аша» сүзләрен өстәргә;

икенче абзацта «бер көн» сүзләрен «бер эш көне» сүзләренә алыштырырга;

4 бүлектә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Административ регламент үтәлешен тикшереп тору формалары»;

4.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр әлеге Регламентның белешмәлек кушымтасында китерелгән.»;

5 бүлектә:

бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт яки муниципаль хезмәткәрләре, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе»;

5.2 пунктның бишенче абзацында «дәүләт хезмәте» сүзләреннән соң «210-ФЗ номерлы федераль законның $15^1$ статьясында күрсәтелгән гариза» сүзләрен өстәргә;»;

$1^1$ кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы пенсионерларының аерым категорияләрен ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юллама алу өчен исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына $1^1$ кушымта

Үрнәк

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы ____________________ муниципаль районы яисә шәһәр округының социаль яклау идарәсе (бүлеге) җитәкчесенә

кемнән

________________________________________,
(Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта).

булып торам ______________________________
(мөрәҗәгать итүченең категориясе)

Паспорт, серия _________ №________________

Кайчан, кем тарафыннан бирелгән ___________________________

СНИЛС[1] ________________________________

Яшәү урыны буенча теркәлү адресы____________________________________

_______________________________________

Факттагы яшәү адресы

__________________________________________

Телефоннар:

өй: _______________________________

мобиль: _______________________________

e-mail:_____________________________________

Ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юллама белән тәэмин итүгә гариза

Сездән үтенәм: ______________________________________________________

(Ф.И.А. (соңгысы – булган очракта) тулысынча).

ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юллама алу өчен белешмә нигезендә шифаханә-курорт дәвалануыына юллама белән тәэмин итүгез турында, форма No. 070 / у _______________ ______________________________.

(дата) (авыру коды)

Мөрәҗәгать итүче милегендәге мөлкәт булуы турында белешмәләр[2]:

| | | |
|---|---|---|
| 1. Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт теркәвенә алынырга тиешле, мәйданы 40 квадрат метрдан артып китә торган торак урын (торак урынның бер өлеше), | ☐ бар | ☐ юк |
| Шул исәптән: | | |
| 1.1. Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән, законнар нигезендә бергә яшәү мөмкинлеген бирми торган хроник авыруның катлаулы формасыннан интегүче кеше яши торган торак урын (шул исәптән фатирда изоляцияләнгән аерым торак урын мәйданы) мәйданы; | ☐ бар | ☐ юк |
| | ☐ мәйданын күрсәтергә | |
| 1.2. билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип танылган торак урыны. | ☐ | ☐ |
| 2. Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт теркәве узарга тиешле торак урын (торак урынның бер өлеше), аның мәйданы ялгыз яшәүче мөрәҗәгать итүчегә исәпләгәндә 80 квадрат метрдан артып китә. | ☐ бар | ☐ юк |
| 3. гомуми мәйданы ялгыз яшәүче гражданинга исәпләгәндә 40 квадрат метрдан артып китә торган, ә ике һәм аннан күбрәк кешедән торган гаиләгә гаиләнең һәр әгъзасына 23 квадрат метрдан артып китә торган, Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт | ☐ бар | ☐ юк |

---
[1] Тутыру өчен мәҗбүри түгел

[2] мөлкәтнең булуы "V" билгесе белән билгеләнә; мөлкәтнең булмавы "X" билгесе белән билгеләнә

теркәвенә алынырга тиешле ике һәм аннан күбрәк торак урыннары (торак урыннарының өлешләре),

Шул исәптән:

3.1. Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән, законнар нигезендә бергә яшәү мөмкинлеген бирми торган хроник авыруның катлаулы формасыннан интегүче кеше яши торган торак урын (шул исәптән фатирда изоляцияләнгән аерым торак урын мәйданы) мәйданы;

☐ бар ☐ юк

☐ мәйданын күрсәтергә

3.2. Билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип танылган торак урын.

☐ бар ☐ юк

4. Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт теркәвенә алынырга тиешле һәм торак урын булып тормаган биналар, төзелмәләр, корылмалар (бина, төзелеш, корылма өлешләре) (транспорт чараларын  (гараж, машина урыны) урнаштыру өчен билгеләнгән күчемсез милек объектларыннан, индивидуаль торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен билгеләнгән җир кишәрлекләрендә, бакча җир кишәрлекләрендә урнашкан хуҗалык корылмаларыннан тыш, аларның мәйданнары 15 квадрат метрдан артмаса, башка җир кишәрлекләрендә урнашкан, мәйданы 15 квадрат метрдан артмаган, күпфатирлы йортларда, гараж комплексларында урнашкан торак булмаган биналардан, шулай ук әлеге нигезләмәнең «г» пунктында санап үтелгән объектлардан тыш);

☐ бар ☐ юк

5. Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт теркәвенә алынырга тиешле, хуҗалык корылмалары булмаган, гомуми мәйданы 40 квадрат метрдан артып китә торган бер яки берничә бакча йорты, дача (бакча) төзелеше объектлары;

☐ бар ☐ юк

6. Россия Федерациясе законнары нигезендә теркәлгән автомобиль, автобус, үзйөрешле машина, пневматик һәм чылбырлы механизм, самолет, вертолет, теплоход, яхта, җилкәнле судно, катер, снегоход, моточана, гидроцикл, тарттырыла торган үзйөрешле булмаган судно, суда һәм һавада йөри торган башка төрле чара (утыру өчен биштән артык урыны булган һәм дүрт һәм аннан күбрәк балалы күпбалалы гаиләләр тарафыннан алынган (сатып алынган) җиңел автомобильдән тыш);

☐ бар ☐ юк

7. мөрәҗәгать итү көненә чыгарылган елы өчтән артмаган ике һәм аннан күбрәк җиңел автомобиль (инвалид тарафыннан файдалану өчен махсус

☐ бар ☐ юк

җиһазландырылган җиңел автомобильдән тыш, утыру өчен биштән артык урыны булган һәм дүрт һәм аннан күбрәк балалы күпбалалы гаиләләр тарафыннан алынган (сатып алынган) җиңел автомобильдән тыш);

8. Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт теркәвенә алынырга тиешле, гомуми мәйданы (суммар мәйданы) 0,2 гектардан артып китә торган бер яки берничә җир кишәрлеге;

☐ бар ☐ юк

☐ мәйданын күрсәтергә

Тәкъдим ителгән мәгълүматларның һәм документларның дөреслеген раслыйм.

Мәгълүмат алу, шул исәптән ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалануына юллама белән тәэмин итү яисә ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалануына юллама бирүдән баш тарту турында, килешәм.

Түбәндәгечә белдерүгә риза:

почта адресы буенча язма формада: ________________________________ ______________________________________________________________________________;

телефонга СМС-хәбәр итеп: _____________________________________________;

электрон почта адресы буенча электрон документ рәвешендә: ___________ ______________________________________________________________________;

шәхси кабинет аша Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында: _________________________________________________.

Миңа шифаханә-курорт дәвалавына юллама белән тәэмин итүгә, шулай ук мәгълүмат бирүгә кагылышлы нинди дә булса үзгәрешләр (адресы, телефоны һ.б.) булган очракта, бу хакта Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы ____________________ муниципаль районы яисә шәһәр округындагы социаль яклау идарәсенә (бүлегенә) хәбәр итәргә кирәклеге турында белдерелде.

«__» ___________ 20____ ел. _______________ ___________________________________
(имза) (Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта)

Гаризаны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасының _____________________ муниципаль районы яисә шәһәр округындагы социаль яклау бүлеге белгече кабул итте.

Мөрәҗәгать итүченең шәхесен раслаучы документтагы белешмәләр тикшерелде.

_____ нөсхә санында теркәлгән документлар белән гариза кабул ителде һәм теркәлде «__» __________ №_______.

«__» _________ 20__ ел. ____________ ____________________________________
(Белгечнең имзасы) (фамилиясе, исеме, ата исеме (соңгысы – булган очракта)

______________________________ кисү линиясе ________________________________

Язу

Гариза (кемнән) ________________________________________________

(Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта).

(кемгә) _________________________________________юллама бирү өчен

(Фамилия, исем, ата исеме (соңгысы – булган очракта).

шифаханә-курорт дәвалавына юллама алу өчен белешмә нигезендә шифаханә-курорт дәвалануына юллама белән тәэмин итүгез турында, форма No. 070 / у

_____________ __________________________________________________

(дата) (авыру коды)

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасының __________________ муниципаль районы яисә шәһәр округындагы социаль яклау бүлеге белгече кабул итте.

«__» ________ 20__ ел. _________ ____________________________________

(Белгечнең имзасы) (фамилиясе, исеме, ата исеме (соңгысы – булган очракта)».